**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге
Фермы Сәүкле торак пунктында 2026 елда гражданнарга
үзара салым кертү турында

2025 елның 21 ноябре № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Фермы Сәүкле торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Фермы Сәүкле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хәрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1)Фермы Сәүкле торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырткычларын урнаштыру (лампаларны, энергия саклаучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча түләү);

2) Ферма Саукле торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _____________ Ю.Г.Антонов